| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |

№ 119/о

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

«10» 09 2019

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен күпфатирлы һәм торак йортларда салкын, кайнар су белән тәэмин итү һәм агынты суны агызу буенча коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын раслау турында» 2012 елның 21 августындагы 131/о номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен күпфатирлы һәм торак йортларда салкын, кайнар су белән тәэмин итү һәм агынты суны агызу буенча коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын раслау турында» 2012 елның 21 августындагы 131/о номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2013 елның 20 маендагы 62/о номерлы, 2017 елның 5 маендагы 95/о номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту максатларында коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын билгеләү һәм ачыклау кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 23 маендагы 306 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-

коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә боерык бирәм: »;

6 пунктта «министр урынбасары» сүзләрен «министрның беренче урынбасары» сүзләренә алмаштырырга;

Әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен күпфатирлы һәм торак йортларда кайнар су белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларында:

«Кама Аланы» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Питрәч | | | | 3,27» | | | | |

таблицадан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Искәрмә. Душ бүлмәләре белән җиһазландырылмаган тулай торакларда кайнар су белән тәэмин итүдән файдалану нормативын 0,94 куб. м күләмендә кулланырга.»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту максатларында салкын һәм кайнар су коммуналь ресурсларыннан файдалану нормативларының 1 пунктындагы «Торак урыннарының категориясе» графасында «кайнар су белән тәэмин итү» сүзләреннән соң «, шулай ук күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гомуми мөлкәте составына керә торган җайланмалардан файдаланып җитештерелгән кайнар су белән тәэмин итү» сүзләрен өстәргә.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы мөдире Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

Министр И.Ә.Фәйзуллин